| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВАХИТОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ВАХИТОВ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
| 20.11.2018 | д. им. М. Вахитова | № 54 |

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2018 елның 19 ноябрендәге 298 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитеты

карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан районының Вахитов авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Вахитов авыл җирлеге башлыгы урынбасары М. К. Идиятуллин

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 20 ноябрендәге
54 номерлы карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге гражданнарына үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә 2019 елның 01 апреленә кадәр гамәлгә ашырыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары

түләү күләме җирле референдум карарында (гражданнар җыенында) билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр түбәндәгеләр булырга мөмкин:

а) хезмәткә сәләтсезлек,

гражданнарга гариза нигезендә түләүне кичектереп тору өч айдан да артык булмаган вакытка бирелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнарга түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисапны башкару хокукына ия оешмалар аша Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр https://uslugi.tatarstan.ru/ порталы аша почта тәрҗемәләрен (исәп-хисап оешмаларын) гамәлгә ашыруга хокуклы булган оешмалар аша акчалар күчерү юлы белән башкарыла.

8. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 20 ноябрендәге
54 номерлы карарына
2 кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________
үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне бюджетка түләү турында

______________________
(муниципаль берәмлек исеме)

Түләүче Ф.И.А ________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
___________________________________________________________ нигезендә
Сезгә _______________________ вакытына кадәр бер тапкыр акча түләргә кирәк
___________________________________________________ чараларны тормышка ашыру
өчен _____________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча:__________________________________________________
Алучының банк БИК ______________________________________
Сч. № __________________________________
Алучының сч. №__ . _________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО__________________
Түләү билгеләү
______________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ________________________________________
М. п. (имза) (имза расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.О _______________________________________________________
Адрес:
__________________________________________________________________________
Алдым «__» _______________ 20__ ел _____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Аермалы корешок тутырыла һәм хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырылса, _______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала*